ПӘНҖЕШӘМБЕ
21 ЯНВАРЬ
1943 ел.
№ 17 (6739)
Аерым номеры 20 тиен.

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) ның ТАТАРСТАН ӨЛКӘ һӘМ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЛАРЫ, ТАССР ВЕРХОВНЫЙ СОВЕТЫ һӘМ ХЕЗМӘТ ИЯЛӘРЕ ДЕПУТАТЛАРЫНЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ ОРГАНЫ



ЛЕНИН БАЙРАГЫ АСТЫНДА АЛГА, ЯҢА ҖИҢҮЛӘРГӘ!

Ленин! Кадерле исем бу. Ул бөтен дөнья хезмәт ияләренең йөрәгендә—иң саф урында саклана, мәңге онытылмаслык изге исем ул! Даһи Ленинның үлүенә бүген 19 ел тулды. Безнең арабызда Владимир Ильич юк. Ләкин аның эше яши, мәңге яшәр ул! Большевиклар партиясе җитәкчелегендә, сөекле юлбашчыбыз, атабыз һәм остазыбыз бөек Сталин җитәкчелегендә Ильич васыятьләре үтәлә, тайпылышсыз һәм өзлекле рәвештә үтәлә.

Патша Россиясенең иң каты һәм котырынган режимы шартларында, В. И. Ленин безнең партиябезне — большевиклар партиясен төзеде һәм эксплоататор сыйныфларга каршы каты көрәштә тәрбияләде һәм граниттай нык итеп чыныктырды. Даһи Ленин дәүләтнең яңа формасын—Совет дәүләтен, совет строен ачты, хезмәт ияләре властен урнаштырды. Әгәр дә инде безнең ныклы, бер вакытта да какшамас строебыз бар икән, совет халкының мәкерле һәм явыз дошманга каршы бөек Ватан сугышында барлык авыр сынауларны үткән шундый куәтле строй бар икән,—моңа без, барыннан да элек, даһи Ленинга бурычлыбыз, аның эшен турылыклы дәвам иттерүче сөекле юлбашчыбыз иптәш Сталинга бурычлыбыз.

Ленин, социалистик Ватанны күз алмасы кебек кадерләп саклау—ул, һәрбер хезмәт иясенең иң беренче һәм мактаулы бурычы, дип өйрәтте. Социалистик Ватанны дошманнардан саклаудан да өстен торган бурыч юк. Совет дәүләте халыкларының азатлыгын һәм бәйсезлеген тәэмин итүдән дә изгерәк булган эш юк. Бөек Ленин әнә шулай диде. Хезмәт ияләренә культуралы, шатлыклы һәм бәхетле тормыш тәэмин итү өчен илнең үсешен яңа ладка—социалистик ладка салу кирәклеген, илне аграр илдән индустриаль ил итеп, машина техникасына корылган яңа, эре социалистик авыл хуҗалыгына ия булган ил итеп әверелдерү кирәклеген күрсәтте.

Гражданнар сугышының иң авыр шартларында В. И. Ленин безнең Кызыл Армиябезне төзеде, яшь Совет иленең кораллы көчләрен үстерде һәм чыныктырды. Большевиклар партиясе җитәкчелегендәге совет халкына безнең Кызыл Армиябезне, Кызыл Флотыбызны ныгыта барырга, илебезнең какшамас оборонасын төзүгә чакырды Бөек Ленин эшчеләр һәм крестьяннар союзын ныгытырга, илебез халыклары арасындагы туганлык һәм дуслык җепләрен ныгытырга чакырды.

Большевиклар партиясе җитәкчелегендәге, сөекле юлбашчыбыз иптәш Сталин җитәкчелегендәге совет халкы Ильич васыятьләрен намус белән үтәде һәм үти. В. И. Ленин идеяләре тормышка ашырылды һәм ашырыла. Илебез танымаслык булып үзгәрде. Инде безнең илебез патша Россиясе иле түгел, артка калган хәерче ил түгел, ә бәлки көчле һәм куәтле индустриаль ил булып, колхоз державасы булып, дөньяда иң культуралы ил булып әверелде. Моны бөек Ватан сугышының авыр сынауларын үткән һәм үтә торган безнең строебыз ачык раслады.

Безнең гүзәл илебезне гитлерчы өерләр «яшен тизлеге» белән басып алырга һәм совет кешеләрен немец бароннарының һәм алпавытларының күндәм коллары итеп әверелдерергә теләделәр. Кабахәт немец этләренең теләге барып чыкмады һәм бер вакытта да барып чыкмас! Ленин—Сталин партиясе тәрбияләгән совет халкы бер вакытта да кол булмас!

Гитлерчы бандитлар шайкасы үз исәпләрендә хурлыклы рәвештә ялгышты һәм аның барлык планнары җимерелде. Даһи Ленин төзегән данлыклы Кызыл Армия сөекле юлбашчыбыз, даһи полководец иптәш Сталин җитәкчелегендә үз бурычларын намус белән үти һәм илебезне немец-фашист басып алучылардан чистарта, дошманны кыйный һәм кыра.

Кызыл Армия җиңүле рәвештә алга бара. Дошман үзенең җанлы көчләрен һәм техникасын калдырып артка тәгәри. Дистәләрчә шәһәрләр, йөзләрчә авыллар немец шакшыларыннан чистартыла. Радио һәр көн саен шатлыклы хәбәрләр китерә.

Ленин шәһәре дә чолганыштан чыгарылды. Һич шик юк: дошман юк ителер. Моңа фронт белән тыл бердәмлеге, Ленин—Сталин партиясе тирәсенә, Совет хөкүмәте тирәсенә нык тупланган совет халкы бердәмлеге ныклы ышаныч бирә.

Алга, Ленин байрагы астында, бөек Сталин җитәкчелегендә яңа җиңүләргә, дошманны тәмам тар-мар итүгә!

СССР СОВНАРКОМЫНДА

СССР Совнаркомы 1943 нче елның 24 нче январендагы ял көнен якшәмбе көннән 1943 нче елның 23 нче январена шимбә көнгә күчерергә карар бирде.

Соңгы сәгатьтә

БЕЗНЕҢ ГАСКӘРЛӘР КӨНЬЯКТА ОСТРОГОЖСК, НЕВИННОМЫССК, ПРОЛЕТАРСКАЯ ШӘҺӘРЛӘРЕН, БЕЛОКУРАКИНО һӘМ БЕЛОВОДСК РАЙОН ҮЗӘКЛӘРЕН АЛДЫЛАР

1. 20 нче январьда ВОРОНЕЖ ФРОНТЫ гаскәрләре дошманның чолганып алынган гарнизонының каршылык күрсәтүен бастырдылар һәм ОСТРОГОЖСК шәһәрен алдылар. Бик күп трофейлар, шул исәптән автомашиналар төялгән 2 тимер юл эшелоны кулга төшерелде.

2. КӨНЬЯК-КӨНБАТЫШ ФРОНТ гаскәрләре, һөҗүмне җәелдерүне дәвам иттереп, район үзәге һәм зур тимер юл станциясе БЕЛОКУРАКИНОНЫ һәм район үзәге БЕЛОВОДСКИНЫ алдылар.

3. КӨНЬЯК ФРОНТ гаскәрләре, кискен атака нәтиҗәсендә, ПРОЛЕТАРСКАЯ шәһәрен һәм зур тимер юл станциясен алдылар. МАНЫЧ КАНАЛЫНЫҢ төньяк яры бөтен буена немец-фашист гаскәрләрдән чистартылды.

4. ЗАКАВКАЗЬЕ ФРОНТЫ гаскәрләре, каты сугыш нәтиҗәсендә, НЕВИННОМЫССК шәһәрен һәм зур тимер юл станциясен алдылар.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫ.

СССР Верховный Советы Президиумы *УКАЗЫ*

РСФСР СОСТАВЫНДА УЛЬЯНОВСК ӨЛКӘСЕ ТӨЗҮ ТУРЫНДА

Ульяновск өлкәсе төзү турында Россия Совет Федератив Социалистик Республикасы Верховный Советы Президиумы тарафыннан кертелгән тәкъдимне расларга. Аның үзәге Ульяновск шәһәрендә була.

Ульяновск өлкәсе составына түбәндәгеләрне кертергә: Ульяновск һәм Мәләкәс шәһәрләре һәм Куйбышев өлкәсе составыннан бүленгән Астрадамов, Базарлы Сызган, Барыш, Богдашкино, Вешкаймский, Инза, Карсун, Кузоватов, Майна, Кече Канда лы, Мәләкәс, Николо-Чермшан, Яңа Малыклы, Яңа Спас, Павлово, Радищев, Сенгилей, Иске Кулатка, Иске Майна, Сура, Тагайский, Теренгульский, Ульяновск, Чардаклы районнары һәм Пенза өлкәсе составыннан бүленгән Баранов һәм Николаевский районнары.

СССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. КАЛИНИН.
СССР Верховный Советы Президиумы Секретаре А. ГОРКИН.

Москва, Кремль.
19 январь, 1943 ел.

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты сәкретаре иптәш КОЛЫБАНОВКА
Татарстан АССР Верховный Советы Президиумы председателе иптәш ДИНМӨХӘМЕТОВКА
Татарстан АССР Совнаркомы председателе иптәш ГАФИЯТУЛЛИНГА
ВЛКСМ ның Татарстан Өлкә Комитеты сәкретаре иптәш ЛУЦКЕРГА

Украина партизаннары турында кайгыртучанлык күрсәткән өчен Татарстан комсомолецларына, яшьләренә һәм барлык хезмәт ияләренә чын күңелдән рәхмәт һәм ялкынлы туганлык сәламе тапшыруыгызны үтенәбез.

Украина партизаннары турында сезнең кайгыртуыгыз Украинаны азат итү эшенең бөек ватаныбыздагы барлык эшчеләргә, колхозчыларга, интеллигенциягә туган һәм якын эш икәнлегенә яңа дәлил, халыкларның какшамас сталинчыл дуслыгының ачык дәлиле.

Украина халкы, СССР дагы барлык халыклар белән берлектә, сөекле юлбашчыбыз иптәш Сталинның доклады һәм приказы белән рухланып, совет җирен фашист ерткычлардан тәмам азат итү өчен аяусыз көрәшә.

Украина халкының меңнәрчә иң яхшы уллары һәм кызлары, партизан отрядлары булып берләшеп, немец оккупантларга каршы бик каты сугышлар алып баралар.

Җибәргән бүләкләре һәм күрсәткән туганнарча ярдәмнәре өчен партизаннар һәм бөтен Украина халкы исеменнән Татарстан хезмәт ияләренә чын күңелдән рәхмәт әйтәбез.

Хезмәт фронтында сезгә яңа уңышлар телибез.

Немец оккупантларга үлем!

Яшәсен бөек юлбашчыбыз һәм полководецыбыз, туганыбыз Сталин!

Украина ССР Верховный Советы Президиумы Председателе М. ГРЕЧУХА.
Украина ССР Совнаркомы председателе Л. КОРНИЕЦ.
Украина КП(б) Үзәк Комитеты секретаре Н. ХРУЩЕВ.
Украина ЛКСМ Үзәк Комитеты секретаре Я. ХОМЕНКО.

БЕЛДЕРҮ

21 нче январьда, кичке 7 сәгатьтә, Татар дәүләт академия театры бинасында партия, совет, профсоюз һәм комсомол оешмаларының В. И. Ленинның үлүенә 19 ел тулуга багышланган тантаналы-траур утырышы була.

Билетларны ВКП(б) райкомнарыннан алырга.

Г. АЛЕКСАНДРОВ

ЛЕНИН — БЕЗНЕҢ ВАТАНЫБЫЗНЫҢ БӨЕК ПАТРИОТЫ

Бөек остазыбыз һәм юлбашчыбыз Владимир Ильич Ленинның үлүенә 19 ел тулды. Лениннан башка безнең халкыбыз, безнең данлыклы партиябез үткән бөтен юл Владимир Ильичның мәңгелек идеяләре белән яктыртылды. Бөтен дөнья күләмендә тарихи әһәмияте булган зур вакыйгалар белән тулган бу 19 елның һәрбер чрында партиябез, халкыбыз үзләренең күз карашларын һәрвакытта да, иптәш Сталин белән бергәләп безнең партиябезне төзегән кешегә, илебезнең халыкларын Октябрь революциясенең казанышларына китергән кешегә, халыклар һәм дәүләтләр тормышы тарихында беренче буларак яңа тормыш нигезләрен иҗат итүнең бөек планын төзегән кешегә юнәлдерделәр. Дәүләтебез алдына, совет кешеләре алдына яңа авыр бурычлар килеп басканда, илебездә катлаулы хәлләр туганда без һәрвакытта да остазыбызның даһилыгына мөрәҗәгать иттек һәм тормыш тарафыннан яңа куелган сорауларга аннан җаваплар таптык. Иптәш Сталин безнең халкыбызга болай диде:

«Ильичны, остазыбызны, юлбашчыбызны истә тотыгыз, яратыгыз, өйрәнегез.

Ильич кебек көрәшегез һәм эчке һәм тышкы дошманнарны җиңегез.

Яңа тормышны, яңа көнкүрешне, яңа культураны Ильичча төзегез. Эштә кечкенә нәрсәләрдән баш тартмагыз, чөнки кечкенә нәрсәләрдән зур нәрсә төзелә,—Ильичның иң әһәмиятле васыятьләреннән берсе шул».

Бу елларның барысында да, җимереклекне, сугышның нәтиҗәләрен бетерү елларында, куәтле социалистик промышленность һәм авыл хуҗалыгы төзү елларында, Советлар Союзының бөек индустриаль-колхоз державасы булып әверелүе елларында безнең халкыбыз, үзенең тормышын Ильичча төзеп һәм халкыбызның явыз дошманнарына каршы көрәшне Владимир Ильич Ленин өйрәткәнчә оештырып, иптәш Сталинның бу күрсәтмәсен изге итеп үтәде.

Безнең партиябез, безнең халкыбыз һәрбер нәрсәдә үз юлбашчысының васыятьләре буенча эш итә һәм безнең бөек көчебез шунда ки, без үз эшебезнең дөреслегенә булган какшамас ышанычыбызны шуннан алабыз. Безнең партиябез хәзерге заманның эчке һәм тышкы политикасының иң катлаулы һәм чуалчык мәсьәләләренә, шул исәптән сугыш чоры политикасы мәсьәләләренә җавапларны Ленин идеяләреннән таба. Безнең партиябез, Ильич васыятьләре белән барып, куәтле дәүләт төзеде. Бу дәүләт сугышның барлык сынауларыннан үтте һәм безнең дошманнарыбыз нинди генә күчәрләргә, коалицияләргә һәм союзларга берләшмәсеннәр, бу дәүләт дошманны җиңәргә сәләтле.

Без юлбашчыбызның һәм остазыбызның бездән китүе көнен искә алган чакта ел саен Ленинның җиңүгә чакыра торган якты образын искә алабыз. Ильичның характерында һәм дөньяга карашында иң уңайсыз һәм авыр шартларда да үзенең ватанын дошманнардан саклап калырга, күп еллык хезмәт һәм кан белән табылган казанышларын сакларга сәләтле булган халык массасының яшәүчәнлегенә һәм иҗат көченә гаять тирәнтен ышанудан да көчлерәк сыйфат булмагандыр. Ленин безнең халкыбызның

В. И. ЛЕНИН.

Художник КАРПОВ РӘСЕМЕ

оештыру, иҗат һәм сугышчан сәләтенә чиктән тыш ышанучы кеше иде. Ул безгә ватанны яратырга, аны сакларга, халкыбызның барлык казанышларын нинди генә дошманнан да саклап калырга васыять әйтте. Ильичның бу васыятьләре безнең өчен изге. Иптәш Сталин Ленинның массага югартын карарга һәм аны бары тик китаплар буенча гына өйрәтергә тырышкан барлык кешеләрдән көлгәнлеген һәм аларны чыбыркылаганлыгын берничә тапкырлар әйтте. Ул, Ленинның «массадан өйрәнергә, аның хәрәкәтләренең мәгънәсенә төшенергә, масса көрәшенең практик тәҗрибәсен җентекләп өйрәнергә» дип һәрвакыт өйрәтеп килгәнлеген әйтте. Иптәш Сталин, массаның иҗат көченә ышану, ул—Ленинның эшендә аңа стихиянең мәгънәсен аңларга һәм аның хәрәкәтен социалистик революция юлына корып җибәрергә мөмкинлек биргән үзенчәлек, диде. Ленин, унарча еллар буена безнең халкыбызда ватанга мәхәббәт тәрбияләде, ватанның бөек тарихы өчен, аның традицияләре өчен, күп еллар, күп буыннар буена безнең халкыбыз эшләгән барлык нәрсәләр өчен көрәшкә ялкынлы мәхәббәт тәрбияләде. Ленин үзенең бөтен гомере буена безнең халкыбызның тарихи казанышларының кадерен белмәүчеләргә, бу казанышларны көндәлек тормышта, көрәштә саклап калмаучыларга каршы барыннан да ныграк көрәште.

Моннан 30 ел чамасы элек, 1914 нче елның 12 нче декабрендә большевикларның «Социал-демократ» газетасында «Великороссларның милли горурлыгы турында» дигән мәкаләсендә Ленин болай дип язды: «Безгә, аңлы великоросс пролетарийларына, милли горурлык хисе чит нәрсәме? Билгеле, чит түгел! Без үз телебезне һәм үз ватаныбызны яратабыз, без аның хезмәт ияләре массасын (ягъни аның халкының 9/10 өлешен) аңлы демократлар һәм социалистлар тормышы дәрәҗәсенә күтәрү өстендә эшлибез. Безгә патша палачларының, дворяннарның һәм капиталистларның безнең гүзәл ватаныбызны нинди көчләүләргә, изүгә һәм мыскыллауларга дучар итүләрен күрү һәм хис итү барыннан да авыррак»*). Аннан соң Ленин, без һәртөрле изүчеләрнең көчләүләре безнең арабызда, великоросслар арасында отпор китереп чыгарганлыкка, бу халыкның Радищевны, декабристларны, 70 нче елларның разночинец-революционерларын биргәнлегенә, 1905 нче елны великоросс эшчеләре сыйныфының массаның куәтле революцион партиясе төзегәнлегенә, великоросс крестьянының демократ була башлаганлыгына, изүчеләрне бәреп төшерә башлаганлыгына горурланабыз, — диде.

Һәм чыннан да, бөек ватаныбызның тарихына күз төшерү белән үк безнең халкыбызның аңа гомуми ихтирам һәм мәңгелек дан китергән хисапсыз күп казанышларының нәрсәдән гыйбарәт икәнлеген ачык күрергә мөмкин. Ни өчен без рус халкы вәкилләре булуыбыз белән горурланабыз, безнең милли горурлыгыбыз нәрсәдә, безнең ялкынлы һәм сүнмәслек патриотлыгыбызның чишмәсе кайда? Хәзерге заман цивилизациясе һәм Европа халыкларының һәм дәүләтләренең культура тормышы таңында ук үз ватанын, дәүләт төзелешен, башка халыклардан өйрәнү һәм башка дәүләтләргә алдынгы тарихи тәҗрибә бирү сәләтен данлыклы төстә саклау үрнәкләрен тудырган халыкның вәкилләре булуың белән ничек горурланмаска? Үз арасыннан политик эш, фән, әдәбият өлкәсендә Ломоносов, Радищев, декабристлар, Пушкин, Герцен, Чернышевский, Добролюбов, Толстой, Сеченов, Плеханов, Павлов, Тимирязев кебек һәръяктан тирән белемле классик акыл ияләрен һәм йөзләрчә, меңнәрчә шундый ук гүзәл һәм бөек башка исемнәрне биргән халыкның вәкилләре булуың белән ничек горурланмаска? Дөньяда иң зур дәүләтнең тарихи үсеше язмышын үз кулына алып күп булса чирек гасыр эчендә изүчеләрдән башка яңа иҗтимагый тәртип урнаштыра алган һәм башка халыклар әле берничә йөз ел буена эшләгән эшне кыска гына вакыт эчендә эшләргә өлгергән халыкның вәкилләре булуың белән ничек горурланмаска? Дәүләтләр тормышында беренче буларак җәмгыятьнең яңа политик төзелеш үрнәкләрен тудырган халыкның вәкилләре булуың белән ничек горурланмаска? Бу җәмгыятьтә эшче, крестьян һәм интеллигент барлык материаль һәм рухани байлыкларны җитештереп кенә калмыйлар, бәлки аларга хуҗа булып та торалар; бу җәмгыятьтә власть башында хезмәт ияләре тора; бу җәмгыятьтә барлык байлыклар һәм халыкның гасырлар буена килгән казанышлары халыкның үзенә бирелгән; бу җәмгыятьтә университетларның һәм мәктәпләрнең ишекләре үзләренең белемнәрен арттыра һәм хәзерге заман фәненең һәм культурасының казанышларын үзләштерергә теләүче һәрбер кеше өчен ачык; бу җәмгыятьтә фән, сәнгать һәм әдәбият беренче тапкыр бөтен халык байлыгы булып әверелде. Үзенең үсеш юлы бөек Ленин һәм Сталин тарафыннан алдан ук күрсәтелгән халыкның бөеклеге белән, азатлык сөюче барлык халыкларның иң көчле, мәкерле, явыз һәм куәтле дошманын—Гитлер Германиясен һәм аның Европадагы иярченнәрен беренче тапкыр җиңгән халыкның бөеклеге белән ничек горурланмаска? Немец-фашист гаскәрләр Европада унлап дәүләт буенча кызу марш белән үттеләр. Алар Европадагы күпчелек халыкларның дәүләт бәйсезлеген һәм культурасын пычракка салып таптадылар. Алар французларга, бельгиялеләргә, норвегиялеләргә, даниялеләргә, румыннарга, венгерларга, югославларга, грекларга, полякларга, чехларга, словакларга һәм башка халыкларга коллык камыты киерттеләр. Ләкин Советлар Союзындагы бөек рус, украин, белорус, грузин һәм башка халыкларның дәүләт бәйсезлеген бастырырга, аларга да фашистик коллык камыты киертергә маташулар шундый көчле җавап удары алдылар ки, бу удар Европа халыкларын гитлеризмга каршы көрәшкә рухландырды һәм безнең алдагы җиңүебез өчен шартлар әзерләде.

---

*) Ленин. XVIII нче том, 81 нче бит.

(Ахыры 3 нче биттә).

ВКП(б) ӨЛКӘ КОМИТЕТЫНДА

Тельман районы колхозларында, совхозларында һәм МТС ында язгы чәчүгә әзерлекнең барышы турында

Тельман районы колхозларында, совхозларында һәм МТС ында язгы чәчүгә әзерлек бөтенләй канәгатьләнмәслек бара һәм тулысынча үз агымына куелган. ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросы, бу мәсьәләне тикшереп чыкканнан соң түбәндәгеләрне күрсәтеп үтте: мондый хәл район башкарма комитеты председателе иптәш Семеновның, ВКП(б) райкомы секретаре иптәш Ивановның, район җир бүлеге мөдире иптәш Соловьевның, совхоз һәм МТС директорлары Фәхретдинов, Кравчук һәм Курдюков иптәшләрнең җавапсыз караулары һәм һичбер гафу ителмәслек гамьсезлекләре нәтиҗәсендә килеп чыккан.

Райондагы күп кенә колхозларда орлыклык участоклардан алынган ашлыкны сугу әле һаман да тәмамланмаган, орлыклык материал салу һәм әзерләү чиктән тыш акрын бара. Бөртекле культураларның салынган орлыкларыннан бары 34 проценты гына чистартылган, 47 колхоздан бары 24 колхоз гына үзләренең орлыкларын контроль-орлык лабораториясенә анализга биргән. Орлыкка бәрәңге кисентеләре әзерләү эшенә әле керешмәгәннәр.

Шуның белән бергә, кайбер колхозларда (Ворошилов исемендәге, Пинин исемендәге, «Урал» колхозларында), контроль булмау һәм гамьсезлек нәтиҗәсендә орлыкларның әрәм-шәрәм ителүе һәм бозылуы фактлары бар.

Кышкы агротехника чаралары гадәттән тыш начар үткәрелә: тирес чыгару планы 12,9 процентка, кар тоту 15 процентка, көл җыю 21 процентка, кош тизәге җыю 3 процентка гына үтәлгән, ә торф әзерләү хәтта башланмаган да. Үткәрелә торган агротехника чараларының сыйфтына контроль алып барылмый, агротехниканы өйрәнү эше оештырылмаган.

Ат инвентарена ремонт ясау эше дә начар тора: 15 колхозда әле чәчү машиналарына ремонт ясауга керешмәгәннәр, 34 колхозда сабаннарга һәм культиваторларга ремонт башланмаган.

ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросы МТС һәм совхозларда тракторларга һәм тагылма инветарьга ремонт ясау темпларының акрын икәнлеген аеруча күрсәтеп үтте. Шушы елның 10 нчы январена Тельман МТС ында 61 трактордан 24 тракторга, «МЮД» совхозында 24 трактордан 11 тракторга, Төрнәс совхозында 26 трактордан бары 6 тракторга гына ремонт ясалган. МТС та тагылма машиналарның 34 процентына, совхозларда 23 процентына гына ремонт ясалган.

Райондагы МТС та һәм совхозларда да, шулай ук колхозларда да машиналар тәртипсез саклана лар. МТС та гына да 6 трактор, 7 комбайн, 13 молотилка усадьбага кайтарылмаган, ә күп кенә колхозларда (Киров исемендәге, Ворошилов исемендәге һәм башка колхозларда) шактый күп чәчү машиналары, культиваторлар һәм башка машиналар кар астында калдырылганнар.

МТС ка һәм совхозларга механизатор кадрлар һәм колхозлар өчен массовый кадрлар әзерләү планын үтәү өзелү куркынычы астында тора: МТС янындагы курсларга укучылар 42 процентка гына, Төрнәс совхозында 60 процентка һәм район колхоз мәктәбендә 20 процентка гына тупланган.

Атлар тиешенчә тәрбияләнмәгәнлектән һәм алардан файдалану дөрес оештырылмаганлыктан үткән елны район колхозларында күп кенә атлар үлгән һәм күп кенә бияләр колын салганнар.

Тельман районы колхозларының, совхозларының һәм МТС ының язгы чәчүгә әзерлекләре шушындый канәгатьләнмәслек хәлдә булуга район советы башкарма комитетының, ВКП(б) райкомының, район җир бүлегенең, МТС һәм совхоз директорларының һәм политбүлек начальникларының үткән елгы ялгышлардан сабак алмаулары һәм быелгы язгы чәчүгә әзерлектә эшлексезлек күрсәтүләре сәбәп булган.

ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросы Тельман район советы башкарма комитеты председателе иптәш И. С. Семеновка һәм район җир бүлеге мөдире иптәш П. Е. Соловьевка аларның 1943 нче елгы язгы чәчүгә әзерлеккә гадәттән тыш начар җитәкчелек итүләрен күрсәтеп үтте һәм алардан бу кимчелекләрне бетерү өчен барлык кирәкле чараларны күрүне таләп итте.

ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросы ВКП(б) ның Тельман райкомы секретаре иптәш Ивановка, район советы башкарма комитеты председателе иптәш Семеновка, район җир бүлеге мөдире иптәш Соловьевка, МТС һәм совхоз директорларына һәм политбүлекләрнең начальникларына, колхозларның председательләренә түбәндәге чараларны үткәрергә кушты:

а) барлык ашлыкларны бик тизлек белән сугып бетерергә; барлык колхозларда һәм совхозларда бөртекле, техник, яшелчә һәм башка культураларның, шулай ук бәрәңге орлыкларын, СССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының «1942 нче елны игеннәрне урып-җыю һәм авыл хуҗалыгы продуктлары әзерләү турында» гы карарына тулысынча туры китереп салуны һәм әзерләүне 15 нче февральдән соңга калмыйча тәмам итәргә һәм орлыкларны тиешенчә саклауны оештырырга; барлык колхозларда орлык өчен бәрәңге кисентеләре әзерләүне җәеп җибәрергә, билгеләнгән планны тулысынча үтәргә;

б) барлык колхозларда звеноларны 2 атна срок эчендә яңадан оештырырга, аларга участоклар беркетергә һәм кышкы агротехника чаралары планын һәрбер кырчылык бригадаларына һәм звеноларына җиткерергә, эшнең сыйфатына һәм һәрбер колхозның, совхозның, бригаданың һәм звеноның планын һичбер сүзсез үтәвенә каты контроль куярга;

в) МТС һәм совхозларда тракторларга һәм тагылма инвентарьга ремонт ясауны 1 нче апрельдән соңга калмыйча, колхозларда гади авыл хуҗалыгы машиналарына һәм инвентарьга (чәчү машиналарына, сабаннарга, тырмаларга, арбаларга һәм башкаларга) ремонт ясауны 20 нче мартка тәмам итәргә; тракторларга һәм авыл хуҗалыгы машиналарына ремонт ясауның сыйфатын җентекләп күзәтеп торуны оештырырга, тикшерү һәм кабул итү вакытында табылган кимчелекләрне бик тизлек белән төзәтергә;

г) СССР Совнаркомы һәм ВКП(б) Үзәк Комитеты карарына туры китереп, призыв (мобилизация) исәбенә, механизация мәктәпләренә, тракторчылар һәм комбайнчылар, механиклар, бригадирлар әзерләү курсларына иң яхшы колхозчылардан, колхозчы хатын-кызлардан һәм совхоз эшчеләреннән бик тизлек белән укучылар тупларга;

д) колхозчыларның, совхоз һәм МТС эшчеләренең, стахановчылык мәктәпләре һәм курслары аркылы, агротехниканы өйрәнүләрен җәеп җибәрергә, авыл хуҗалыгы алдынгыларының, бөтенсоюз авыл хуҗалыгы күргәзмәсендә катнашучыларның тәҗрибәсеннән киң күләмдә файдаланырга;

е) 20 нче мартка газогенераторлы тракторлар өчен җитәрлек кадәр санда шакмаклар әзерләргә, яракландырырга, киптерергә һәм эш урыннарына илтергә;

ж) язгы кыр эшләре башлануга эш атларын һәм үгезләрне әзерләүне тәэмин итәргә; барлык колхозларда даими ат караучылар билгеләп куярга, яраксызларны тикшерелгән колхозчылар һәм колхозчы хатын-кызлар белән алыштырырга, барлык атларны ат караучылар җаваплылыгына бирергә һәм ат йөртүчеләргә атларны индивидуаль тәртиптә беркетергә; хәлсез һәм авыру атларны аерым группага аерып куярга, аларны үзләренә аерым тәрбияләргә һәм ашатырга.

ВКП(б) Өлкә Комитеты бюросы партия райкомын, район советы башкарма комитетын, МТС һәм совхоз политбүлекләрен, партиянең һәм комсомолның башлангыч оешмаларын, колхозларда, совхозларда һәм МТС та массовый политик эшне тамырыннан яхшыртырга, 1943 нче елны югары уңыш алу өчен барлык көчләрне туплауга аеруча игътибар бирергә, МТС, совхозлар, колхозлар, бригадалар, звенолар, аерым колхозчылар, МТС һәм совхоз эшчеләре арасында социалистик ярышны киң күләмдә җәеп җибәрергә, алынган йөкләмәләрнең үтәлүен кара-каршы тикшерүне системалы рәвештә үткәрергә мәҗбүр итте.

Язгы чәчүгә әзерлек эшендә югарыда әйтелгән кимчелекләр республиканың күп кенә башка районнарында да булганлыктан ВКП(б) Өлкә Комитеты ВКП(б) райкомнары секретарьларын, район башкарма комитетлары председательләрен, МТС һәм совхоз политбүлекләре начальникларын барлык кимчелекләрне бик тизлек белән бетерергә һәм 1943 нче елгы язгы чәчүгә үрнәк булырлык төстә әзерләнү өчен тулы чаралар күрергә мәҗбүр итте.

БАЛАЛАР ӨЧЕН АШХАНӘ

Хезмәт ияләре депутатларының Казан шәһәр советы башкарма комитеты карары буенча шәһәрдә балалар өчен яңа ашханәләр ачылды. Бу ашханәләрдә 6 меңгә якын бала тукланa. Шул исәптән Бауман районында 900 балалык, Молотов районында 1.200, Свердлов районында 950, Сталин районында 850 балалык ашханәләр оештырылды.

Бу ашханәләргә балаларны сайлап җибәрү өчен шәһәрнең барлык районнарында махсус комиссияләр төзелде. Шәһәр сәүдә бүлегенә балалар ашханәләрен ит, ярма, он, икмәк, май, бәрәңге, яшелчә һәм башка продуктлар белән тоткарсыз тәэмин итеп торырга тәкъдим ителде.

ЛЕНИН — БЕЗНЕҢ ВАТАНЫБЫЗНЫҢ БӨЕК ПАТРИОТЫ

(Ахыры. Башы 2 нче биттә).

Без, совет кешеләре, Кызыл Армия һәм Кызыл Флот сугышчылары һәм командирлары, совет фабрикаларының һәм заводларының эшчеләре, техниклары һәм инженерлары, колхозчылар һәм колхозчы хатын-кызлар, галимнәр, артистлар, художниклар, музыкантлар, архитекторлар, ватаныбыз өчен дәһшәтле булган бу сәгатьтә бөек халыкның һәм үзенең тарихы бөтен дөнья цивилизациясе һәм культурасы тарихына алтын сүзләр белән язылган бөек ватанның вәкилләре булуыбыз белән горурланабыз. Ленин, безне ватаныбызның чын күңелдән бирелгән патриотлары булырга өйрәтте. Ә безнең заманда чын патриот булу, бөек Ленин эзеннән бару, бөек остазыбыз, сөекле юлбашчыбыз иптәш Сталин җитәкчелегендә эшләү һәм көрәшү—бертуктаусыз тормыштан өйрәнү дигән сүз, дошманның кара көчләрен халкыбызның җиңүе өчен ватаныбыз бәхетенә җиң сызганып эшләү дигән сүз.

Гражданнар сугышы вакытында Совет дәүләтенең хәле көннән-көн авырая башлагач Ленин, партиябезгә, бөтен совет халкына мөрәҗәгать итеп, бездә чыннан да куәтле һәм бай Русь иле төзү генә түгел, бәлки аны саклап калу өчен кешеләрнең көч запасында да, халык иҗатына бөек революция биргән гүзәл көлачта да материаль һәм табигый байлыклар бар, диде. Моның өчен, диде Владимир Ильич, һәртөрле боеклыкны һәм һәртөрле бушка сөйләүләрне читкә алып ташларга, үзебезнең барлык көчләребезне җыярга, һәрбер нервны җигәргә, һәрбер мускулны киерергә, җиңелүләрдән рухны төшермичә алга барырга, социалистик җәмгыятькә таза нигез салырга, дисциплина булдыру өстендә, һәркайда да оешканлыкны, тәртипне, эшлеклелекне, бөтен халык көчләренең бергәләшеп эшләвен, производствода гомуми учетны һәм контрольне, продуктларны бүлүне ныгыту өстендә җиң сызганып эшләргә кирәк—хәрби куәт һәм социалистик куәт төзүгә бару юлы әнә шул.

Ватаныбызның чын патриоты булу—Ленинның бу бөек васыятен тайпылышсыз үтәү дигән сүз, һәрвакыт һәм һәрнәрсәдә, һәрбер гражданин тормышның һәм көрәшнең кайсы гына тармагына куелса да — ул Кызыл Армия сугышчысы яки командирымы, эшче яки колхозчымы, яисә акыл хезмәте кешесеме—һәрвакыт Ленин васыятенә иярергә дигән сүз. Иптәш Сталин бездән дәүләтебезнең куәтен көн саен арттыра торган, ватаныбызны саклап калуда һәм дошманга кискен удар ясауда ярдәм итәрлек хәрби, экономик һәм культура көчләрен көн саен арттырырлык патриотлыкны, ватаныбызга чын күңелдән бирелгәнлекне һәм мәхәббәтне таләп итә.

Данлыклы бөек ватаныбызга лаеклы кешеләр булыйк! Дәүләтебезне дошманнардан саклау буенча үзебезнең эшебездә юлбашчыларыбыздан—Лениннан һәм Сталиннан һәрвакыт үрнәк алыйк. Шул чагында безнең халкыбыз өчен беркинди дошман да, ул безнең ватаныбызга никадәр ярсуланып һәм явызланып һөҗүм итсә дә, куркыныч булмас! Ватаныбыз каршындагы бурычыбызны ахырынача үтик, дошман урдаларын рәхимсез рәвештә тармар итик, совет җирен явыз оккупантлардан чистартыйк. Героик армиябезгә җиңү өчен кирәк булган бөтен нәрсәне бирү өчен җиң сызганып эшлик. Ленин һәм Сталин партиясе тирәсенә сафларыбызны тагын да тыгызрак туплыйк һәм, партиябез байрагы астында, дошманны җиңүне яулап алыйк.

СОВЕТ ИНФОРМБЮРОСЫННАН

20 нче ЯНВАРЬДАГЫ ИРТӘНГЕ БЕЛДЕРҮ

20 нче январьга каршы төндә безнең гаскәрләр Сталинград районында, Воронеждан көньяктарак, Төньяк Кавказда, Донның түбәнге агымы, Төньяк Донец районында һәм Ладога күленнән көньяктарак элекке юнәлешләрдә сугышларны дәвам иттерделәр.

* * *

Сталинград районында шәһәрдән көнбатыштарак хәрәкәт итүче Н-че часть, каты сугышлардан соң дошманның күп кенә ныгытылган позицияләрен алды. 300 гитлерчы юк ителде, 50 немец солдаты һәм офицеры плен алынды. Җиргә казып куелган берничә танк, төрле әйберләр тутырылган 6 склад һәм башка трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Көньяк фронтта безнең гаскәрләр, дошманның каты каршылык күрсәтүен җиңеп һәм аның контратакаларын кире кайтарып, һөҗүмне дәвам иттерделәр. Маныч аркылы кичкән безнең частьлар халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бу пунктларның берсе өчен булган сугышта гитлерчыларның ике ротасы тар-мар ителде. Бер танк, 4 орудие, 13 пулемет, 2 сугыш припаслары склады һәм 14 автомашина кулга төшерелде.

* * *

Көньяк-Көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр алга бардылар. Бер участокта танк подразделениеләре һәм моторлаштырылган подразделениеләр дошман тылына үтеп чыктылар һәм бер төн эчендә немецларның 5 танкысын, танкка каршы ата торган 12 орудиесен һәм 30 автомашинасын юк иттеләр. Икенче бер участокта, Төньяк Донец районында, безнең частьлар халык яши торган берничә пунктны алдылар. 600 гә якын немец солдатлары һәм офицерлары юк ителде, дошманның 8 танкысы яндырылды һәм зарарланды. Трофейлар кулга төшерелде һәм пленныйлар алынды.

* * *

Воронеж фронты гаскәрләре уңышлы һөҗүм сугышлары алып бардылар һәм чолганып алынган дошман дивизияләрен кысуны дәвам иттерделәр. Иптәш Бежко командалыгындагы гвардеецлар халык яши торган берничә пунктны алдылар. Бу пунктлар өчен булган сугышларда 800 дән артык гитлерчы юк ителде. 308 кеше плен алынды. Төрле калибрдагы 47 орудие, 62 кул пулеметы һәм 28 станоклы пулемет кулга төшерелде. Икенче бер участокта безнең гаскәрләр бик күп итальян солдатларын һәм офицерларын плен алдылар.

* * *

Великие Лукидан көньяк-көнбатыштарак безнең частьлар халык яши торган 5 пунктны алдылар. Сугыш кырында дошман үз солдатларының һәм офицерларының йөзләрчә үле гәүдәләрен калдырды. Шуның өстенә немецлар 20 танк һәм 10 орудие югалттылар. Ржевтан көнбатыштарак командиры иптәш Гришин булган артиллерия часте дошманның җыелып тора торган гаскәрләренә каршы ут һөҗүме ясап, дошманның 2 танкысын, 2 артиллерия батареясын юк итте һәм бер батальонга якын пехотасын таркатты.

Совет очучылары һава сугышында немецларның 5 самолетын бәреп төшерделәр.

* * *

Төньяк Кавказда безнең гаскәрләр сугыша-сугыша алга бардылар һәм халык яши торган берничә пунктны алдылар. Н-че часть дошманның чигенү юлын кисте һәм төнге сугышта немецларның бер рота пехотасын тар-мар итте 5 танк һәм 12 автомашина кулга төшерелде. Пленныйлар алынды. Икенче бер участокта безнең кавалеристлар отряды дошман тылына барып чыкты һәм кинәт һөҗүмнәр ясап гитлерчылар арасында паника тудырды. 100 гә якын немецларны кырганнан соң отряд үз частена барып кушылды.

* * *

Ладога күленнән көньяктарак безнең гаскәрләр һөҗүм сугышлары алып баруны дәвам иттерделәр. Н-че часть дошманның көчле рәвештә ныгытылган оборона узелын алды. 12 ДЗОТ һәм 19 блиндаж җимертелде, 5 орудие һәм 11 пулемет юк ителде. Бер танк, 14 орудие, 33 пулемет, 35 автомат, 318 винтовка, 1 сугыш припаслары склады, бер азык склады һәм башка трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Краснодар краенда хәрәкәт итүче партизаннарның бер отряды немецлар кулындагы бер авылга төнлә һөҗүм ясаган. Партизаннар берничә дистә гитлерчыны кырып ташлаганнар һәм бер җиңел машина, бер станоклы пулемет, 40 винтовка һәм 3.000 патрон кулга төшергәннәр.

* * *

Югославия партизаннары бик каты сугышлардан соң Ясеница һәм Лика местечколарын алганнар. 200 гитлерчы плен алынган. 2 миномет, 5 пулемет, 200 винтовка һәм төрле сугыш милекләре кулга төшергән. Загреб-Беловар зонасында хәрәкәт итүче партизаннар 140 дошман солдатын һәм 17 офицерын юк иткәннәр, дошманның 3 поездын шартлатканнар. Партизан моряклар Адриатика диңгезенең көньяк өлешендә итальяннарның азык төялгән 5 кечкенә пароходын кулга төшергәннәр.

20 нче ЯНВАРЬДАГЫ КИЧКЕ БЕЛДЕРҮ

20 нче январьда Воронеж фронты гаскәрләре дошманның чолганып алынган гарнизонының каршылык күрсәтүен бастырдылар һәм **Острогожск** шәһәрен алдылар.

Көньяк-көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр, һөҗүмне җәелдерүне дәвам иттереп, район үзәге һәм зур тимер юл станциясе **Белокуракиноны**, район үзәге **Беловодскины**, халык яши торган зур пунктлардан **Даниловканы**, **Городищены**, **Большая Черниговканы**, **Митякинскаяны** һәм тимер юл станциясе **Чеботовканы** алдылар.

Көньяк фронт гаскәрләре, кискен атака нәтиҗәсендә, **Пролетарская** шәһәрен һәм зур тимер юл станциясен алдылар.

Закавказье фронты гаскәрләре, каты сугыш нәтиҗәсендә, **Невинномысск** шәһәрен һәм зур тимер юл станциясен, район үзәге **Икон-Халкны**, тимер юл станциясе **Иркен Шәһәрне**, халык яши торган пунктлардан **Иркен Халкны**, **Клычевскийны** һәм башкаларны алдылар.

* * *

19 нчы январьда безнең авиация частьлары фронтның төрле участокларында дошманның гаскәрләр һәм йөкләр төялгән 120 дән артык автомашинасын юк иттеләр яки зарарладылар, 10 артиллерия батареясының утын бастырдылар, бер сугыш припаслары складын шартлаттылар һәм бер батальонга якын пехотасын таркаттылар һәм бер өлешен юк иттеләр.

* * *

Сталинград районында безнең гаскәрләр немец фашистларының чолганып алынган гаскәрләрен кыруны дәвам иттерделәр. Шәһәрдән көнбатыштарак Н-че часть зур тактик әһәмияте булган бер биеклекне алды һәм анда ныгып урнашты. Шәһәрдә безнең частьлар дошманның берничә контратакасын кире кайтардылар, 200-300 метр алга киттеләр, берничә дистә ДЗОТ ны һәм блиндажны алдылар.

Безнең очучылар аэродромнарда немецларның 4 транспорт самолетын юк иттеләр. Һава сугышларында дошманның 10 самолеты бәреп төшерелде. Шуның өстенә дошманның 3 самолетын безнең сугышчыларыбыз пехота коралларыннан атып төшерделәр.

* * *

Көньяк фронтта безнең гаскәрләр, дошманның каршылык күрсәтүен җиңеп, алга баруларында дәвам иттеләр. Каты сугышлардан соң Н-че берләшмә частьлары Пролетарская шәһәрен һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Немецлар сугыш кырында үз солдатларының һәм офицерларының йөзләрчә үле гәүдәләрен һәм бик күп санда төрле сугыш техникасын калдырдылар. Маныч аша кичкән безнең частьлар немецларны халык яши торган тагын берничә пункттан бәреп чыгардылар.

* * *

Көньяк-көнбатыш фронтта безнең гаскәрләр уңышлы һөҗүмне дәвам иттерделәр һәм халык яши торган күп кенә пунктларны алдылар. Горняцкий рудник районында Н-че часть сугышчылары 500 дән артык гитлерчыны юк иттеләр һәм ашлык тутырылган 2 зур складны кулга төшерделәр. Икенче бер участокта безнең танкистлар зур тимер юл станциясе Белокуракиноны алдылар һәм Валуйки-Старобельск тимер юлын кистеләр. Бик күп трофейлар кулга төшерелде. Трофейларның саны алына. Безнең икенче бер частебыз халык яши торган зур пунктка килү юлларында булган сугышта 1.000 нән артык немец солдатларын һәм офицерларын кырып ташлады.

* * *

Воронеждан көньяктарак безнең гаскәрләр барлык юнәлешләрдә һөҗүмне җәелдерделәр. Н-че берләшмә частьлары дошманның көнбатышка чигенү юлын кистеләр һәм чолганып алынган дошман гаскәрләрен юк иттеләр. Халык яши торган дистәләрчә пунктлар алынды 980 дошман солдаты һәм офицеры плен алынды. 93 орудие, шул исәптән 3 авыр артиллерия батареясы, 11 танк, азык һәм сугыш припаслары тутырылган 14 склад, 11 радиостанция, 108 автомашина һәм снарядлар салынган 7.046 ящик кулга төшерелде. Икенче бер юнәлештә Н-че берләшмә частьлары 3.000 нән артык кешене плен алдылар, 32 орудие, гаять күп санда снарядлар һәм миналар, шулай ук йөк төялгән берничә тимер юл эшелоны кулга төшерелде Валуйки-Уразово районында дошманның бер бронепоезды кулга төшерелде. Халык яши торган бер пунктта безнең кавалеристлар дошманның, бөтен материаль часте белән берлектә, бер артиллерия полкын тулы составы белән плен алдылар.

* * *

Төньяк Кавказда совет гаскәрләре, дошманның каршылык күрсәтүен бастырып, алга баруларында дәвам иттеләр һәм халык яши торган уннарча пунктларны алдылар. Тулы булмаган саннар буенча 1.000 гә якын гитлерчы юк ителде. 460 немец солдаты һәм офицеры плен алынды. 100 дән артык орудие, шул исәптән немецларның бер артиллерия полкының барлык орудиеләре, 200 дән артык пулемет, 65 миномет, 50.000 снаряд, 280 автомашина һәм 8 азык склады кулга төшерелде. Командиры иптәш Фролов булган частьның сугышчылары бер су чиген кичтеләр һәм халык яши торган бер зур пунктны алдылар. Дошманның бер батальонга якын пехотасы, 5 танкысы, бер бронемашинасы юк ителде. Еракка ата торган 5 орудие, 4 сугыш припаслары склады һәм башка трофейлар кулга төшерелде.

* * *

Ленинград өлкәсендә хәрәкәт итүче отрядның бер группа партизаннары немецларның бер хәрби эшелонын юлдан чыгарган. Паровоз һәм 16 вагон җимерелгән, Икенче бер отрядның партизаннары 10 көн эчендә дошманның 5 хәрби эшелонын һәлак итүне оештырганнар. 4 паровоз, солдатлар төялгән 7 вагон, сугыш техникасы һәм сугыш припаслары төялгән 16 платформа җимерелгән.

ФРАНЦИЯ ПАТРИОТЛАРЫНЫҢ КӨРӘШЕ

ЛОНДОН, 19 январь. (ТАСС). Сугышучы Франция даирәләренә алынган хәбәргә караганда, Монлюсон шәһәрендә (Алье департаменты) немецлар Франциянең 300 эшчесен Германиягә эшкә җибәргә маташкан вакытта, Германиягә каршы бик зур демонстрация ясалган. Эшчеләрнең мәҗбүри рәвештә Германиягә җибәреләчәкләре турында белгәч, берничә мең французлар вокзалга һәм перронга барып тулганнар һәм «Марсельеза» җырлап, «Лавальга үлем,» һәм «Яшәсен де Голль!» дигән тавышлар белән эшелон янына килгәннәр. Демонстрантларның бер группасы вокзалга килү юлларына урнашкан. Германиянең моторлаштырылган сакчылары вокзалга килеп, халыкны прикладлар белән куа башлаганнар. Немецлар белән французлар арасында бәрелешү булган. Германиягә җибәрелергә билгеләнгән эшчеләр, ыгы-зыгыдан файдаланып, качып киткәннәр.

Югославиядә тимер юл транспортының таркалуы

ИСТАМБУЛ, 19 январь. (ТАСС). Югославия партизаннарының хәрәкәте Югославиядә тимер юл транспортының эшен бөтенләй тукталу дәрәҗәсенә китереп җиткергән. Сентябрь аенда ук Павелич властьлары Хорватия королевствосы дип атала торган территориядә барлык тимер юлларда зур тизлек белән йөкләр йөртүне туктатканнар. Гитлерчылар тарафыннан чыгарыла торган «Дейче цейтунг ин кроатиен» газетасының хәбәр итүенә караганда, декабрь аенда Слоински—Брод-Сараево һәм Великий Градац—Грубишно-Полье-Гарешница линияләрендә поездларның хәрәкәте бөтенләй туктатылган. Павеличның курчак «хөкүмәте» властьлары илнең барлык тимер юлларында йөрүне «билгесез срокка» кадәр тыйганнар.

Тимер юл транспортында һәлакәткә очрау һәм диверсия вакыйгалары бик ешаеп киткән. Павелич властьлары юлларда көчле сакчылар тотарга мәҗбүр булалар. Патрульләргә һәм сакчы постларга һәрвакыт кинәт һөҗүмнәр ясалып тора. Партизаннар часовойларны үтерәләр яки пленга алалар. Загреб-Сараево тимер юлының директоры, немецлар ялчысы Муфтичның әйтүенә караганда, тимер юл буйларында ДОТ лар һәм ДЗОТ лар ясарга туры килгән. Партизаннар поездларга һөҗүм иткән вакытта оккупантлар армиясе өчен сугыш припаслары һәм азык төялгән тимер юл составларын бөтенләй җимерәләр.

Германия авиациясенең Лондонга һөҗүменә карата

ЛОНДОН, 19 январь. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, 18 нче январьга каршы төндә Германия авиациясе Лондонга һөҗүм иткән вакытта 50—60 самолет катнашкан. Беренче һөҗүм 25—30 самолет белән ясалган. Бу самолетлар 20 сәгать белән 22 сәгать арасында Лондон районында күренгәннәр. Бик аз самолетлар гына шәһәр өстенә үтеп керә алганнар. Стратегия ягыннан әһәмиятле объектларга һава һөҗүменнән зарар килмәгән. Халык яши торган кварталларда корбаннар бар, промышленность районнарында зарар артык зур түгел.

Дошман самолетларының икенче группасы да үзенең көче ягыннан шул чамада булган. Ләкин монысында тик берничә самолет кына шәһәр өстенә үтеп керә алган.

ЧИТ ИЛ ХРОНИКАСЫ

—Почта министры Франк Уокер бер тавыштан АКШ тагы демократлар партиясенең председателе итеп сайланган.

—Американың Юнайтед Пресс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, немецлар оккупация ясаганнан бирле Франциядә иң аз дигәндә 50.000 кеше концентрация лагерьларына ябылган.

—Польшада Германия солдатларына һөҗүм итүләрнең ешаеп китүе уңае белән немецлар 2000 полякның кулга алынуы турында Варшава урамнарына игълан ябыштырганнар Игъланда күрсәтелүенә караганда, кулга алынучы поляклар Германия солдатларына һөҗүмнәрдә катнашкан булганнар.

БЕЛДЕРҮ

Ярдәмче хуҗалык директорлары, агрономнары, зоотехникларының һәм промышленность предприятиеләре ОРС начальникларының республика киңәшмәсе 1943 нче елның 25 нче январенда Менжинский исемендәге клубта (Карл Маркс урамы, 26) була. Киңәшмә иртәнге 10 сәгатьтә башлана.

Киңәшмәгә катнашучылар ТАССР Совнаркомы янындагы Госпланда регистрация үтәләр.

Җаваплы редактор урынбасары **ГАЛИМ РЯБКОВ.**

Редакциянең телефон номерлары: җаваплы редактор—АТС 73—27, редактор урынбасары—АТС 76—29. секретарь—АТС 79—29. Партия тормышы бүлеге 14—75, промышленность-транспорт һәм хатлар бүлеге АТС 75—55, авыл хуҗалыгы бүлеге АТС 76—14, типография 36—60.

ПФ 619 «КРАСНАЯ ТАТАРИЯ» һәм «КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН» издательствосының АЛЕКСАНДРОВ ИСЕМЕНДӘГЕ ТИПОГРАФИЯСЕ № Заказ 1284